ПРОЕКТ

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
СОВЕТЫ

КАРАР

2015 елның 13 октябре №___

«Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты хакында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 29 статьясындагы 1 пунктының 1 пунктчасы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

**1) 7 статьяның 1 пунктында:**

**а) 15 пунктчада** «, шул исәптән сатып алу юлы белән,» сүзләрен төшереп калдырырга;

**б) 26 пунктчаны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«26) Район территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, районның рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;»;

**в)** түбәндәге эчтәлекле **36 пунктча өстәргә:**

«36) «Дәүләт күчемсез мөлкәт кадастры турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә комплекслы кадастр эшләре башкаруны оештыру һәм территориянең карта-планын раслау.»;

**2) 18 статьяның 4 пунктына** «Татарстан Республикасы законы нигезендә» сүзләрен өстәргә.»;

**3) 44 статьяда:**

**а) 3 пунктка түбәндәге эчтәлекле унөченче абзац өстәргә:**

“Дәүләт күчемсез милек кадастры турында” 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә комплекслы кадастр эшләре башкаруда катнаша һәм территориянең карта-планын раслый;”;

**б) 5 пунктта алтынчы абзацны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Район территориясендә физик культура, мәктәп спорты һәм массакүләм спорт үсеше өчен шартлар тәэмин итә, районның рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын уздыруны оештыра;”;

**в) 9 пунктта алтынчы абзацны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларына, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларына, муниципаль хезмәткәрләргә һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренә һөнәри белем һәм өстәмә һөнәри белем бирә, мәгариф турында Россия Федерациясе законнарында һәм муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә муниципаль хезмәт өчен кадрлар әзерләүне оештыра.»;

**4) 70 статьяга түбәндәге эчтәлекле 2.1 пункт** өстәргә:

«2.1. Район Советы карарларын кабул иткәндә район Башлыгы тавышы район Советы депутаты тавышы буларак исәпкә алына.»;

**5) 73 статьяның 9 пунктына** түбәндәге эчтәлекле сүзләр өстәргә:

«һәм (яисә) хокукый акт текстын «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» Интернет-ресурсында урнаштыру.»;

**6) 92 статьяның 2 пунктында** «аларны тотуга факттагы чыгымнар» сүзләрен «аларның хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнар»сүзләренә алмаштырырга.

3. Әлеге карарны «Туган як»газетасында бастырырга.

4. Карар проекты буенча ачык тыңлауларны 2015 елның 11 ноябренә 10.00 сәгатьтә район мәдәният йортында (тамаша залы) билгеләргә.

Гавами тыңлаулар Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2006 елның 17 октябрендәге 11/6 номерлы карары белән расланган гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибенә ярашлы рәвештә үткәрелә, ул Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Чүпрәле муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырылган.

5. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү буенча муниципаль хокукый акт проекты буенча искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алу Чүпрәле муниципаль районы Советының 2012 елның 25 апрелендәге 18/1 номерлы карары белән расланган Тәртип нигезендә башкарыла.

6. Әлеге проект буенча гражданнарның искәрмәләре һәм тәкъдимнәре 2015 елның 10 ноябренә кадәр Иске Чүпрәле авылы, Үзәк урамы, 13 нче йорт, 114 нче кабинет адресы буенча кабул ителә.

7. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының законлылыкны үтәү һәм җәмәгать тәртибен саклау буенча даими комиссиясе Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы депутатларының төзәтмәләрен һәм гражданнарның карар проектына тәкъдимнәрен өйрәнергә һәм гомумиләштерергә, карар проектын эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы каравына кертергә.

8. Әлеге карар, гамәлдәге законнарда билгеләнгән башка срокларда үз көченә керә торган нигезләмәләрдән тыш, рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы Советы Рәисе: А.В. Шадриков